Шифр ТЯ9 - 09

Задания регионального этапа
Всероссийской олимпиады школьников
по татарскому языку
2017-2018 учебный год
9 класс

Уважаемый участник!

Время проведения олимпиады по татарскому языку в 9-11 классах – 180 минут. Максимальное количество баллов – 50 баллов.

Ответы на задания I _части_ заносятся в таблицу ответов.

| Инструкция по выполнению работы |
|---|
| При выполнении заданий в Таблице ответов под номером выполняемого вами задания поставьте знак «Х» в клеточку, которая соответствует букве выбранного вами ответа. |

Таблица ответов

| | 1.1 | 1.2 | 1.3 | 1.4 | 1.5 | 1.6 | 1.7 | 1.8 | 1.9 | 1.10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) | X + | | | | X + | | | X + | | X − |
| 2) | | X + | X + | X + | | X − | | | | |
| 3) | | | | | | | X − | | X + | |
| 4) | | | | | | | | | | |
| Задания по 1 баллу | | | | | | | | | | 7 б. |

| № | Татар теле | Балл |
|---|---|---|
| I. | Тестлар (дөрес җавапны билгеләгез) | 10 |
| 1.1 | [о] авазы –<br>1) урта күтәрелешле, иренләшкән, кыска, арткы рәт сузыгы;<br>2) урта күтәрелешле, иренләшкән, озын, алгы рәт сузыгы. | 1 |
| 1.2 | Татар телендә кушымчалар ничә вариантта йөри:<br>1) берничә;<br>2) ике: калын һәм нечкә. | 1 |
| 1.3 | Нәрсә ул дифтонг?<br>1) бер иҗек эчендә янәшә килгән ике тартык;<br>2) бер иҗек эчендә килгән ике сузык;<br>3) берничә сүздән бер-бер артлы тезелеп ясала. | 1 |
| 1.4 | Кушма исемнәр...<br>1) ике тамырны теркәп ясала;<br>2) берничә сүздән кушып ясала;<br>3) берничә сүздән бер-бер артлы тезелеп ясала. | 1 |
| 1.5 | Ким җөмлә...<br>1) ким булса да, хәбәр итү үзлегенә ия;<br>2) оешып беткән җөмләгә өстәлеп килгән сүз, сүзтезмә, җөмлә ул; | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) ким булганга, хәбәр итү үзлегенә ия була алмый. | |
| 1.6 | Бүлүче теркәгечләр:<br>1) ләкин, ә, бәлки, әмма, фәкать, тик;<br>2) һәм, да, дә, та, тә, тагы, янә, ни...ни;<br>3) я, яки, яисә. | 1 |
| 1.7 | Исемнәргә ялганган –кай, -кәй, -чык, -чек, - кәш кушымчалары иркәләү һәм кечерәйтүне белдерүче...<br>1) төрләндергеч кушымчалар;<br>2) төр кушымчалары;<br>3) сүз ясагыч кушымчалар. | 1 |
| 1.8 | Бер составлы җөмләләрдә...<br>1) оештыручы үзәк бер генә була, икенчесен өстәп тә булмый;<br>2) оештыручы үзәк ике – ия һәм хәбәр була. | 1 |
| 1.9 | Рәвешнең төп синтаксик функциясе...<br>1) хәбәр;<br>2) аергыч;<br>3) хәл. | 1 |
| 1.10 | Җөмләдә нокталар урынына кайсы килеш кушымчасын куярга кирәк?<br>*Дөнья... матур җирләре күп, ләкин туган яктан да кадерлерәк җир юктыр.*<br>1 )урын- вакыт;<br>2 )юнәлеш;<br>3 )чыгыш;<br>4 )иялек. | 1 |
| 2. | Мәкальләрне дәвам итәргә. | 10 |
| 2.1 | Киемеңне яңа чагыңда, намусыңны...аны чагыннан сакла | 2 |
| 2.2 | Кеше холкын күзәт, үзеңнекен ...рәтлә | 2 |
| 2.3 | Аерылганны аю ашар,..аерылганны бүре ашар | 2 |
| 2.4 | Җиде кат үлчә, ..бер кат кис | 2 |
| 2.5 | Ананың балага биргән иң зур бүләге-.... | 2 – |
| 3. | Текстка нигезләнеп, биремнәрне үтегез. | 10 |
| | (1) Нурлы Аланда иң матур чак, мөгаен, яз көнедер. (2) Язның да әле яңа башланган чагы. (3) Апрель керсә, авыл каршындагы тау түбәсен көн буена кояш нурлары җылытып тора. (4) Беренче булып, кар шунда көпшәкләнә, шунда эри башлый. (5) Урамнарга гөрләвек авазлары кергәнче үк, тау башындагы түбәтәй кадәр урын кышкы җәймәдән арчылып та өлгерә. (6) Малайлар, дөньяларын онытып, шунда йөгерә. (7) Балакларын тез тиңентен сызганып, яланаяк калып, | |

85

| | | |
|---|---|---|
| | кар суларын ерып уйнаклыйлар. (8) Бил тиңентен чишенеп, яңа чыгып килгән яшел чирәм өстендә сузылып ятуның да тәүге рәхәтен шунда, тау башында татый алар. (9) Бөтен дөнья, бөтен әйләнә-тирәне кар сырып алган, ә син тау башындагы яшел чирәм өстендә сузылып ятасың. (10) Язгы кояш нурларында кызынасың. (11) Авылның аргы башындагы олы юлдан тыз-быз машиналар чапканны күзәтәсең. (12) Аларда утырып барган кешеләр күрәме икән Нурлы Алан малайларын? (13) Күрәләр, әлбәттә. (14) Алар нинди бәхетле дип, кызыгып та куялардыр әле. (15) Яшел хәтфә чирәм өстендә уйнап йөргән чакларын исләренә төшереп, эчтән генә сагышланып та куялардыр. (Р.Мөхәммәдиев) (145 сүз)<br><br>*1. 8 – 11 җөмләләр арасында тиңдәш кисәкләр булган җөмләнең номерын күрсәтегез.*<br>9 —<br>*2. 15 нче җөмләдән сыйфатны табыгыз.*<br>Яшел +<br>*3. 8- 11 җөмләләр арасында теркәгечле тезмә кушма җөмләләрнең номерын языгыз.*<br>9 +<br>*4. 1- 4 җөмләләр арасында иярченле шарт җөмләнең номерын күрсәтегез.*<br>3 +<br>*5. 11-15 җөмләләр арасында кереш сүзләр булган җөмләләрнең номерларын языгыз.* 13 +<br>*6. 11 җөмләнең баш кисәген языгыз* күзәтәсең (бер составлы) +<br>*7. 12 җөмләдән хәл фигыльне языгыз.*<br>утырып +<br>*8. 1нче җөмләдән кисәкчәне языгыз.*<br>иң +<br>*9. Парлы сүз булган җөмләләрне күрсәтегез.*<br>9, 11, +<br>*10. 9 җөмләдән алмашлыкны табып , языгыз.*<br>син + | 95 |
| 4. | Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итегез. | 10 |
| 4.1 | Праздники существуют с давних времен и у многих народов.<br>Бәйрәмнәр борын заманнан килгән, алар күп халыкларда бар. | 2 |
| 4.2 | Праздники обогащают знаниями и помогают обмену опытом.<br>Бәйрәмнәр белем бирә, һәм опыт (тәҗрибә) белән алмашырга булышалар. | 2<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 4.3 | Эти дни не только для развлечений и отдыха.<br>Бу көннәр уенарга һәм ял итәргә генә түгел. | 3 |
| 4.4 | В песнях, танцах и играх мы узнаем о людях, истории народа.<br>Җырларда (Җырларда), биюләрдә һәм уенарда, без кеше, халык турында яңа белем алабыз. | 3 |
| 5 | “Сабантуй – халык бәйрәме” дигән темага инша языгыз.<br>Татар халкының бер матур бәйрәме бар. Ул „Сабантуй" дип атала. Бу бәйрәм июньдә үтә. Аңа әйбәт уен табалар. Ул уенның „мәйдән" диләр. Сабантуйга татарлар белән рус, башкорт һәм башка халыклар киләләр.<br>Бездә, Төмәндә, ул бик зур бәйрәм. Без аңа озак әзерләнәбез. Бу көнне ярыш уткәрәләр. Ул „көрәш" дип атала. Көрәштә җиңгән кеше әйбәт бүләк ала. Тагын бер безнең яраткан ярыш – ат чабышы. Аны карарга бик кызыклы. Беренче атта килгән кешегә дә бүләк бирәләр.<br>Сабантуйда башка конкурслар да бар. Аларга балалар да, олы кешеләр дә катнашалар<br>Бөтен татар халык бу бәйрәмне ярата. Без дусларым белән аңа ел саен йөрибез.<br>Сабантуй – халык бәйрәме. Ул кешеләрне якынрак итә. Шулай булып, бөтен Төмән бер халык белән җыела. Сабантуй – борынгы бәйрәм, ул безнең тарихыбыз! | 10 |

10б

10б

итого: 14б